***Мәктәп туры***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2021-2022 нче уку елы)
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 90 минут**
**Максималь балл – 46**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Басымы соңгы иҗеккә төшкән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *татарча*;
   ә) *ничәнче*;
   б) *ашаганчы*;
   в) *укытучы*.

2. Хәрефләр белән авазлар саны тигез булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *егет*;
   ә) *юрган*;
   б) *төньяк;*
   в) *табигать*.

3. Фразеологизмның мәгънәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   *сай йөзү*
   а) *начар йөзү*;
   ә) *оста йөзү*;
   б) *качу*;
   в) *белмәү*.

4. Рус алынмасын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *өстәл*;
   ә) *полиция*;
   б) *концерт*;
   в) *галим.*

5. Кыскартылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *суыткыч*;
   ә) *драмтүгәрәк*;
   б) *җил-буран*;
   в) *дәү әти*.

6. Чама санын билгеләгез. **(2 балл)**

а) *бишенче*;
ә) *икешәр*;
б) *унлап*;
в) *дүртәү*.

7. Рәвешне билгеләгез. **(2 балл)**
а) *җырлый*;
ә) *татар*;
б) *икенче*;
в) *икеләтә*.

8. Билгеләү алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
а) *кем;*
ә) *һәркем;*
б) *кемдер;*
в) *һичкем.*

## II. Теоретик бирем.

Күпнокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(6 балл)**

*Сузык авазлар ике төркемгә бүленә:* **...............** *һәм нечкә. К хәрефе ике авазны белдерә: [*__.....__*], [къ]. Сүзлекләр төзү турындагы фән* **......................** *дип атала. Парлы сүзләр һәрвакыт* **..................** *аша языла. XX, VI –* **............** *цифрлары. Сап-сары –* **............................** *дәрәҗәсендәге сыйфат.*

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. **(16 балл)**

*У нас есть кошка. Её зовут Мурка. Мурка чёрная, только лапки и хвостик белые. Шёрстка мягкая. Хвост длинный, пушистый, а глаза жёлтые, как огоньки.*

*У Мурки пять котят. Мурка и котята живут в корзинке. Корзина у них очень большая. Всем котятам удобно и тепло.*

*Ночью Мурка охотиться на мышей, а котята сладко спят.*

2. Сез нинди йорт хайванын яратасыз? Шул хакта 8 җөмлә төзеп языгыз. **(8 балл)**